ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
№22

Карар
18.09. 2019ел.

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Башкарма комитеты К А Р А Р Б И Р Д Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Усали торак пунктындагы Үзәк урамда су белән тәэмин итү системасын үзгәртү( траншея казу, материал, торбалар сатып алу, договор буенча хезмәт күрсәтүгә түләү) ;

- Владимир торак пунктында Октябрь урамы буенча баручы юлны, Югары Берсут торак пунктында Җиңү урамы буенча баручы юлны, Бөрсет-Сукачы

торак пунктында Яшьләр урамы буенча баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;

- Авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту:

Усали авылы; Югары Кыерлы авылы;Владимир авылы ;Бөрсет-Сукачы авылы;Дружба поселогы;Күк-Чишмә авылы;

-Усали торак пункты зиратын әйләндереп алу өчен материаллар кайтарту;( торбалар, профнастил калай сатып алу)

- Лампалар, яктырту җиһазларын кайтарту, договор буенча хезмәт күрсәтүгә түләү.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башлыгы А.И.Зиатдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.И.Зиатдинов